
# идел 1



# ИДЕЛ

ЯШЬЛӘРНЕҢ
ӘДӘБИ АЛЬМАНАХЫ

1



ТАТАРСТАН
КИТАП НӘШРИЯТЫ
КАЗАН 1970

БУ САНДА:

**В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга**

Г. Рәхим, Ф. Шәфигуллин шигырьләре

**Татарстанның 50 еллыгын каршылап**

Ә. Рәшитов, Р. Мингалимов, З. Шакиров әсәрләре

**Проза, драматургия, поэзия**

М. Маликова, Х. Хәлилов, Ф. Садриев, К. Сибгатуллин, И. Бәдертдинов, Зөлфәт, Г. Сәгыйров әсәрләре.

**Әдәби берләшмәләрдән**

Түбән Кама. «Кама таңнары» нәрсәләр вәгъдә итә?
Р. Хисмәтуллин, К. Гыйльмуллин, З. Сәмигуллин, Ф. Сафин, Р. Имаев, Ф. Гыйззәтуллина, Н. Нуретдинов, М. Хәбибуллин.

**Казан дәүләт университеты яшьләренә сүз бирелә**

Р. Хуҗин, Р. Ягъфаров, Р. Бәшәров, К. Шәйхетдинов.

**Тәнкыйть-библиография, әдәбият тарихы**

М. Госманов, Х. Зарипов мәкаләләре

**Сәнгатьме, фәнме, әллә!..**

Б. Галиев. Музыканың төсе

**Яшьләр көлә**

Т. Мин, К. Шәйхетдинов пародияләре

Ф. Шәфигуллин, М. Мәһдиев, М. Маликова, В. Нуруллин кебек үзенчәлекле яшьләрдән башка тулы булмас иде шикелле. Алар хаклы рәвештә үзләренә мәйдан даулыйлар. Язучылар союзы органы булган «Казан утлары» журналы, күләме артуга да карамастан, яшь иҗат көчләренең барысына да тиешенчә урын биреп бетерә алмый, әлбәттә. Яшь әдипләребез янына яшь композиторларыбызны, художникларыбызны, артистларыбызны, җырчыларыбызны, галимнәребезне дә өстәсәк, яңа мәйданның зарурилыгы шиксездер.


Әдәбият-сәнгать өлкәсендә алмаш тәрбияләү — бөтен җәмәгатьчелек эше. Шунлыктан КПССның Татарстан өлкә комитеты, Язучылар союзы идарәсе белән берлектә, яшьләр өчен альманах чыгаруны кирәк тапты. Моннан ун еллар элек чыгып килгән һәм кайбер сәбәпләр аркасында тукталып калган «Идел» альманахын яңарту дигән сүз бу.

Халкыбыз иҗат интеллигенциясеннән, шул исәптән яшьләрдән дә, чын халыкчан сәнгать әсәрләре көтә. Альманах редколлегиясе иҗат дәрте белән янып яшәүче яшьләргә бу өлкәдә зур өметләр баглый һәм аларны альманах битләренә чакыра. Кунак булып түгел, хуҗа булып килегез, яшь көчләр!

Хәерле сәгатьтә!



# В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУГА



Гәрәй Рәхим

## ИЛЬИЧКА

Безнең буын җиргә киләсене
Ничә еллар алдан күргәнсең!
Безгә, көрәшчеләр токымына
Комсомол дип исем биргәнсең.
Мин әйтергә телим шул токымнан
Иң гади бер вәкил буларак:
Көрәшләрдә синең васыятьләр
Безгә иң беренче чыганак.
Кешеләрчә, сабыр көрәшәбез
Йодрык-мазар төйнәми генә.
Без гигантлар күтәрәбез илдә
Купшы сүзләр сөйләми генә.

Безнең өчен синең кешелегең
Иң, иң бөек өлге буларак —
Тимер ныклык өчен синең рухың
Безгә иң беренче чыганак.
Менә шулай чыныгабыз, Ильич,
Өйрәнәбез эшлеклелеккә.
Без эш белән генә турылыклы
Бу Тормышка, Идеал, Иреккә.
Шушы буын җиргә киләсене
Ничә еллар алдан күргәнсең!
Безгә, көрәшчеләр токымына,
Комсомол дип исем биргәнсең.

Фаил Шәфигуллин


## УЭЛЛСКА ХАТ

Исәнмесез, Уэллс,
Ул чагында
(Белмим ничек кенә сыйганбыз)
Ил белән бит...
Ильич күзләреннән
Карап торган идек сиңа без.
Романнарың матур...
Тик һаман да
Бер төер бар безнең күңелдә.
Хәтерлимсең, Кызыл мәйдан
сулышын,
Бөек Акыл тавышын Кремльдә.

Күрәлсәң дә кешелек даһиеның
Даһи сүзләр әйткән бер мәлен,
Еллар аша карый белмәдең син,
Ул күргәнне күрә белмәдең.
Чыгалмассың барыбер очларына
Плотиналар буйлап йөгермә.
Романнарың матур,
Тик һаман да
Сиңа рәнҗү яши күңелдә.
«Кремль хыялчысы» хакында син
Ни уйлыйсың хәзер, я, сөйлә.
...Ул чагында киләчәктән килеп
Карап торган идек без сиңа.



# ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП



үзе җырлый алмады. Ул моны дусларына васыять итеп әйтеп калдырды, — диде әлеге юлчы.

Юллар, юллар, мине туган йорттан
Аерып ерак алып киттегез.
Җитәр инде, озак кунак булдым,
Хәзер кире өйгә илтегез...

Юлчы Мусаның әманәтен безгә җиткерде. Бу җыр герой-шагыйрьнең менә шушы юлга багышланган моңлы җыры иде.

— Ә менә монысы сезнең өчен,— диде Мусаның дусты чишмә белән сандугачка эндәшеп.

Сандугач күңелен нечкәртеп, чишмәне иркәләп, яңа җыр агыла башлады:

Һәр иртә сандугач
Чишмәдә коена,
Бу аңа чиксез зур
Дан булып тоела.

Иркәли таң кошын
Зөбәрҗәт тамчылар.
Әйтче, бу күренешкә
Сокланмый кем чыдар?

Җыр тәмам булып, җир өсте тынганда, чишмә чылтыравы бу моңны еракларга таратып өлгергән иде инде.

Бераз утырганнан соң юлчы:

— Мусаның тагын бер теләге бар иде. Үлгәч үзен менә шушы юл башына, туган җиренә күмәргә васыять әйткән иде. Чылтырап аккан чишмә тавышын, карт имәннең җилдә шаулавын, алсу таңда сандугач сайравын — барысын да тыңлармын, дигән иде ул. Ләкин явыз дошман аның каберен кеше таба алмаслык итеп яшерде. Шуңа күрә, без, аның дуслары, юл башына, туган авылына аның һәйкәлен куярга булдык,— диде.


Барлык юллар арасында иң данлы юл бу хәзер. Батыр якташыбызның һәйкәле шушы юл башында, аның туган авылы — Мостафа авылының басу капкасы янында, нәкъ мин аны беренче мәртәбә очраткандагыча горурланып, алга ашкынып тора. Аның янына, туган җиренә бертуктаусыз халык агыла. Мин аларны горурланып каршы алам һәм озатып калам...

Карт имән тынды. Ул әле хикәясен сөйләп бетермәгәндер дип, мин сүзсез генә имән төбендә утыра бирдем.

Шул вакыт сандугач сайравы ишетелде. Әйе, бу ул, Муса җырлаган сандугач, карт имәннең дус сандугачы иде! Ул Муса җырларыннан илһам алып яши. Ул туган җире, кыю якташлары, зур батырлык юлы турында җырлый иде...



# ПРОЗА, ДРАМАТУРГИЯ, ПОЭЗИЯ



Бик зур яңалыгыбыз бар, улым. Светлананы кияүгә бирдек! — Ул үзенең кызын биргәндәй шатлана иде.

Мин дә Рәисә апага йөрәк сыкравымны, башымның әйләнүен сиздермәскә тырышып, тешләремне кыстым, тыштан шатланган булдым.

— Бәхетләре булсын инде...


— Булыр, булыр. Бик пар килгәннәр. Ире бик сөйкемле, эчми, тартмый. Үзебезнең авыл малае. Институт бетергәч, каядыр читкә җибәргәннәр иде, хәзер Әлмәттә тора икән. Туйлары зрә күңелле үтте. Светлана гына бераз елап алды, анысы шатлыктан булгандыр инде.

— Ә син, Рәисә апа, кияү чырае күрмичә картая, дигән идең.


— Дигәнмендер, дигәнмендер. Ни әйтсәң дә, утызы җитеп килә иде. Кемнедер көтеп яшәгән, имеш. Ә көткәне алдаган, күрәсең.— Учындагы кортлы чикләвекләрне идән юа торган чиләккә салып, зарланырга тотынды: — Быелгысы елларда чикләвекләр нык кортлап китте. Минә, без кыз вакытта, бер дә кортлы булмый торган иде ул. Кара инде, адәм хуры! Бер кәрҗиннән нибары ике стакан савы чыкты. — Рәисә апа стенадагы ике герле, хан заманыннан калган зур гына сәгатькә карап алды да: — Бәрәкәт, ни гомер юанганмын, — дип, стаканнарын алъяпкычына бушатты. — Светланаларның китәр вакытлары. Ул чикләвекне бик ярата, бераз күчтәнәч булыр диюем. Мин озакламам, хәзер кайтып җитәрмен...

Өстәл өстендә чикләвекләр ятып калды. Көзге чикләвекләр. Сап-сарылар. Читтән караганда бар да тук, таза кебек күренәләр. Кулыңа алып әйләндереп-әйләндереп карамыйча, аерып ал, бар: кайсы тук та кайсы кортлы...

Түбән Кама.



# КАЗАН ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ ЯШЬЛӘРЕНӘ СҮЗ БИРЕЛӘ



## КАЗ ӨМӘСЕ

Каз мамыгы — тупсада.
Өмәнең кызган чагы.
Кашка куна, керфеккә,
Мамыкның тузган чагы.

Кырын ятып чиләктә,
Бәкегә төшә казлар...
Каз мамыгыдай җиңел
Кара толымлы кызлар.

Гөрләп тора табыннар,
Өмәләре ни тора!
Йортка төшкән яшь килен
Мамык мендәр тутыра.

Рафаэль Хуҗин

## МАЛАЙ ЧАКЛАР


ай чаклар, шаян үсмер чаклар
әләргә калган эләгеп.
аллыклар безгә урман иде,
лгалар — диңгез элгәре.

ы куе таллар арасында
ыш» уйнап йөрдек котырып.
тибрәнгән тополь ботагында
й чагым калган утырып.


буйларында аунап үстек.
решә идек... «Баш киләм!»
ы инеш шаулап аккан җиргә
о чагым чумган баш белән.

й чаклар, шаян үсмер чаклар
ләргә калган эләгеп.
й чакның күп нәрсәсен койган
омышның кыллы иләге.





# ТӘНКЫЙТЬ-БИБЛИОГРАФИЯ, ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ



ның авторы бераз роман-
о күңеленең шушы хасия-
әсерләренә, шигырьләре-
бер серле настроение би-
уенда», «Әлфирә», «Ике
«Тәүге мәхәббәт», «Ана
китерә» — шундыйлар.
а 11 әсәр бар, дүртесендә
больницада бара. Әмма
а моңсулык нурлары си-
(анысын да начар дияргә
якты тәэсир кала.
Яруллин беренче шигырь-
алар өчен язган иде. Дө-
рияткә аяк басканда күп
ыйрьләр шулай итәләр,
ыннан үзләре канат чыгар-
ы оныталар. Бу бик үк мак-
клы хәл түгел үзе, шулай
йрь табигатен көчләү дә
иде. Күз тимәсен, Фәнис
сукмагыннан бөтенләйгә
ды, ул язганнарның күбесе
яшүсмерләргә адреслан-
ты китабы исә — «Минем
улаем балалар өчен. Аның
на бәләкәй генә рецензия
ып чыкты («Казан утлары»,
2 сан). Әйе шул, әлеге ре-
әйтелгәнчә, «балалар өчен
кайбер китаплар бәхетсез
Алар укылмый. Чөнки
шигырьләр, балаларның
беркатлылыгына зурларча
рап елмаеп, зурларга сөй-
булып чыга. Мондый ши-
е тыңлап, зурларның ел-
с мөмкин, әлбәттә... Ә бала
игырьләрне укып чыккан-
лмаерга уйлап та карамая-
и бу шигырьдә сөйләнгән
якыйга — аның өчен таби-
әл генә...» Зөлфәт фикер-
ләре бик дөрес. Ф. Яруллинның күп-челек шигырьләренә кагылышлы рәвештә урынлы әйтә ул. Әмма автор тарафыннан китерелгән мисал бу очракта урынсыз. Зөлфәт карлыгач турындагы шигырьне балалар табигатенә хуш килерлек әсәр итеп ала. Ә шигырь Фәнис Яруллинның вакыт-вакыт «балалардан зурларча өстән карап көлүе»нә дәлил! Чөнки сабый үзенең беркатлылыгы белән «карлыгачның койрыгы ярык, шуннан таныдым...», ди, ул әле барлык карлыгачларның да койрыклары шундый икәнен белеп җиткерми, ә әтисе баласының «аңгыралыгына» гаҗәпләнеп елмаеп тора... Мондый шигырьләрнең шактый еш очравы («Җәй көне дә шуармын», «Төшермәдем», «Бәби кемгә охшаган?», «Бушлай билет саталар») борчу тудыра. Чөнки шундый тенденция гомумән татар балалары өчен язылган шигъри әдәбиятта соңгы чорда нык тамыр җәйде. Бу хәл безне уйланырга мәҗбүр итәргә тиеш.

Фәнис Яруллин шигыренә үз йөрәгенең бер кыйпылчыгын сала, шуңа аның әсәрләре укучы тарафыннан яратып кабул ителә...


Минем Фәнис Яруллинны күргәнем юк. Әмма шигырь китапларын укыгач, аның рухын татыгач, күптәнге танышым кебек сизәм. Менә әле дә ул кояш белән сөйләшәдер, кирле-хутлы атлап йөрүче бәләкәчне күзәтеп, елмаеп утырадыр. Бәлки аның күзе сиреньнәргә төшкәндер. Әллә күңеле белән Ык буйларындамы?

Мин аның моңсулыгын тоям, елмаюын күрәм кебек. Кешелекле елмаюны, Фәнис елмаюын...

●



# СӘНГАТЬМЕ, ФӘНМЕ, ӘЛЛӘ?..



зебезнең «Кристалл»ыбыз кебек
п Мәскәүнең Съездлар сараен
Казандагы яңа концерт залын
әшкә җигәргә була бит. Аларны
төсле музыкаль инструмент итеп
натырга» мөмкин. Әгәр дә әлеге
кның аскы «тарелкасын» төрле
ыкаль әсәрләр өчен экран итеп
далансак? Юк, биредә музыка
нсыз — урам, трамвайлар йөреп
. Тукта, тукта, әгәр төсләрне
ыка белән түгел, ә... һава торы-
белән бәйләп үзгәртсәк?! Бу бит
цыз багучы бүләк иткән алтын
кебек үк булачак. Һәм... әнә,
гыз, циркның аскы «тарелка-
да төсләр салмак кына алышы-
тора: кызылдан — яшелгә,
лдән — зәңгәргә, аннары яңадан
лга... Шундый зур бина «су-
.

әнә җил чыга, анеморумбометр
тлары әйләнә башлый, шунда
алтын әтәч» аваз бирә, аның
ы төсләрдә чагыла. Архитекту-
абигать белән берләшә. Төсләр
хәлендәге үзгәрешләрне күр-
, «сөйләп» торалар...

рынгы Көнчыгыштагы бер канун
төшә. Көннең төрле вакытында,
ң төрле фасылында, һава хәле-
төрле үзгәрешләрендә шул
нтка яраклы музыка гына
рга рөхсәт ителә. Тарих кабат-
. Хәзер һава хәле төсләр музыкасын үзенә буйсындыра.

Әллә каян гына болытлар куерды, яңгыр ява башлады. Урамга ак яктылык сирпелде. Әлеге кызыл-яшел-зәңгәр-кызыл хәзер ак төс белән сыекландырыла һәм бу чиратлашу кара юеш асфальтта кабатланып уйный...

Яңгыр тына, ак төс кими. Җил дә йокыга тала. Түбәдәге «алтын әтәч» канат кагып боерык бирә: отбой, отбой! Төсләр тынып калалар.

Анеморумбометрга аңа нәрсә — яңгырың ни, карың ни, салкының ни, эссең ни! Ә яңгырны ничек үлчәргә? Төсләр бит яңгыр көчәю белән яки кимү белән үзгәрәләр. Егетләрнең берсе гаҗәеп фикер әйтте: үзебезнең приборны яңгыр сулары ага торган трубага куйыйк!

Футурист Маяковский Пушкинга кулын сузды:

— Ә сез ноктюрн уйный алырсызмы су трубаларын флейта итеп?

Безнең изге хыялыбыз бар: Казандагы истәлекле биналарның барысын да шулай цирктагы шикелле төс белән «бизәп» чыгарга иде. Барысын бер үзәктән идарә итеп, — әйтик елга портындагы дамбадан, — бөтен шәһәрне төсле музыкаль инструмент урынына «уйнатырга» булыр иде. Тьфу, тьфу! Күз тимәсен хыялыбызга!



# ЯШЬЛӘР КӨЛӘ



РЕДКОЛЛЕГИЯ

Марс Шабаев (җаваплы редактор), Гариф Ахунов, Аяз Гыйлаҗев, Илтани Илалова, Туфан Миңнуллин, Рафаэль Мостафин, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Хәкимов, Илдар Юзиев, Мирсәет Яруллин, Илдар Әхмәдиев.

Редакторы Резеда Вәлиева

Художнигы С. Кульбака

Художество редакторы А. Садыйков

Техник редакторы Ә. Трофимова

Корректорлары Р. С. Хәмидуллина, М. М. Мирсалихова

Производствога бирелде 28/VIII-1969 ел. Басарга кул куелды 26/III-1970 ел. ПФ 05185. Типография кәгазе № 3, $70 \times 90^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табагы 6,16. Якынча басма табагы 7,02. Заказ В-450. Тираж 3500. Бәясе 21 тиен.

Татарстан китап нәшрияты.
Казан. Бауман ур., 19.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19.